**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.11.2020 Балык Бистәсе штп. № 249пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләре исемлеген раслау турында

“Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында” 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Кушымтага ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләре исемлеген расларга.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 27 маендагы “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге һәм эффектлылыгы күрсәткечләре исемлеген раслау турында” 82пи номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад мәсьәләләре буенча урынбасары В.И.Токрановка йөкләргә.

Җитәкче Р.Л. Исланов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Башкарма комитетының _____елның
___ ____________-дәге (-дагы)____
номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре исемлеге**

Күрсәткечләр:

1. **еллык күрсәткеч:** муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда профилактик чаралар санының узган елга караганда артуы, %.

V= A/B x 100 %

A – агымдагы елда үткәрелгән профилактик чаралар саны;

B – узган елда үткәрелгән профилактик чаралар саны.

2. **еллык күрсәткеч:** төзекләндерү кагыйдәләрен бозганда юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар тарафыннан закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү фактларын киметү, %;

V = (A / B -A1 /B1) x 100

A – узган елда төзелгән актлар (беркетмәләр) саны, берәмл.;

A1 – агымдагы елда төзелгән актлар (беркетмәләр) саны, берәмл.;

B – узган елда уздырылган планлы рейд тикшерүләре саны (системалы мониторинг), бер.;

B1 – агымдагы елда уздырылган планлы рейд тикшерүләре саны (системалы мониторинг), бер.;

3. **квартал күрсәткече:** муниципаль районда контроль төрләренең гомуми саныннан аларны гамәлгә ашыруның административ регламентлары кабул ителгән муниципаль контроль төрләре өлеше, %.

V= A/B x 100 %

A – муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның кабул ителгән административ регламентлары саны;

B – муниципаль контрольнең расланган төрләре.